# Зур теләк кирәк

## Ел ахырында әңгәмә

**1992 нче хуҗалык елы ахырына якынлаша. Һәрбер оешма предприятие, колхоз-совхозлар кебек үк, чагыштырмача яңа берләшмәләр—фермер хуҗалыклары да үз эшләренә йомгак ясыйлар. Без җир ресурслары һәм реформасы буенча район комитеты рәисе Р. Х. ХӘСӘНОВка нәкъ шуларны белешү максаты белән мөрәҗәгать иттек.**

**Рифкать Хатыйпович, районда шундый берләшмәләр күп исәпләнәме?**

—Районда бүгенге көнгә 16 крестьян-фермер хуҗалыгы, 1 крестьян хуҗалыклары ассоциациясе исәпләнә. Алар игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнәләр, арада авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүчеләр дә бар. Хуҗалыкларның күбесе 1991 ел ахырында, 1992 ел башында оешып эшли башлады, шунлыктан тәүге елның нәтиҗәләре алар өчен бик мөһим иде. Ни дисәң дә оешу, өйрәнү чорында кыенлыклар аз очрамады аларга. Инде тәҗрибә туплап өлгергән «Шомыртлык» кебек хуҗалыклар агымдагы елда да стабиль күрсәткечләргә ирештеләр.

—Инде аларга якынрак килсәк...

—Мөмкин. Агымдагы елда крестьян-фермер хуҗалыклары 7357 центнер ашлык, 72 центнер күпьеллык үлән орлыгы, 225 центнер яшелчә, шулай ук терлек азыгы җитештерделәр, аларны өлешчә саттылар, бер өлешен терлекләр өчен азыкка туплап куйдылар. Моннан тыш (әлегә безнең мәгълүматлардан күренгәнчә) 49 центнер ит, 11500 килограмм сөт, 3 центнер 60 килограмм йон, 1 центнер 20 килограмм бал җитештерделәр. Шул ук «Шомыртлык»ның (җитәкчесе Х. Даутов) 68 гектар җире, 80 баштан артык мөгезле эре терлеге бар. Әлегә алар малларны тапшырырга өлгермәделәр, ә үз участокларыннан 370 центнер ашлык, 450 центнер печән җыеп алдылар, аны сусыл азык буларак та кулландылар. Елны уңышлы төгәлләгән хуҗалыкларга Кормыш авылыннан Х. Тәмаевның «Аргамаг»ын, Чулпаннан М. Нәбиуллинның «Чирмешән»ен, Яңа Әмзәдән И. Нәбиуллинның «Батыр» ассоциациясен, Кикеледән И. Мостафинның «Тегермән»ен дә әйтергә була. «Аргамак» 1010 центнер ашлык, 40 центнер күпьеллык үлән орлыгы, «Чирмешән» 32 центнер костер орлыгы, 450 центнер печән җитештерде, моннан тыш аның 50 баш сарыгы, 5—6 баш мөгезле эре терлеге бар, киләчәктә алар мөгезле эре терлек санын арттырырга, яшелчәчелек белән дә шөгыльләнергә җыеналар. «Тегермән» 520 центнер бодай үстерде. Хәзер он тарттырып сата. Мин алар елны әйбәт төгәлләделәр дип шикләнмичә әйтә алам.

**—Рифкать Хатыйпович, шул ук вакытта бик үк нык дип саналмаган хуҗалыклар да бар бугай бит әле...**

—Андыйлар да бар. Үзегез күреп торасыз: хәзерге экономик четреклелек, тотрыксызлык чорында бик уйлап, алдан исәпләп эшләсәң генә отарга мөмкин. Шуның өстенә, кечкенә генә нюансның да аяк чалуы ихтимал. Әйтик, Мамык авылыннан Иванның «Брейн-Ринг» хуҗалыгы һич кенә дә «Сөлчә» совхозы дирекциясе белән уртак тел тапмый. Конфликтлар еш чыга, тегеләре фермер хуҗалыгы җиренә көтү кертүгә кадәр барып җиттеләр. Чулпаннан Г. Хәлимовның «Сафкино» хуҗалыгы белән «40 лет Победы» колхозы идарәсе арасында да шундый ук хәл күзәтелә. Билгеле, бу ике як өчен дә зыянга гына, бигрәк тә фермерлар өчен. Ни дисәң дә хуҗалыклардан техника белән дә, башкасы белән дә ярдәм кирәк була бит әле. Дөрес, «Шомыртлык», «Чулпан», «Чирмешән» республика крестьян хуҗалыгы ассоциациясе аша, «Батыр», «Аргамак» гамәлдән чыккан техника ремонтлап үзләренә кирәкле техниканы туплый алдылар. Әмма күбесе әле бу яктан мактана алмыйлар. Аннан фермер хуҗалыгы җитәкчеләренә белем дә (бәлки омтылыш та), җир белән эшләүдә тәҗрибә җитмәү дә үзен сиздерә. «Союз» (А. Филимонов), «Сафкино», «Содружество», «Брейн-Ринг», «Таң» әлегә авыррак баралар. Әйтик, «Таң» үзендә җитештерелгән яшелчәсен сатарга килешү дә төземәгән булган, шунлыктан ул аны үз вакытында файдалы итеп тапшыра алмый интекте. Андый кыенлыклар күп очрап тора әле.

**—Ә аларын хәл итүдә фермерларның төп киңәшчесе кем соң?**

—Менә бу—иң авырткан җир. Эш шунда: фермерлык хәрәкәте, кызганычка каршы, бездә тулысы белән диярлек үзагымга куелган әле. Биредә фермерларның үзләрендә дә гаеп бар. Алардан инициатива җитми, бездән—игътибар. Бер тапкыр районда фермерлар ассоциациясе төзү турында сүз кузгатылган иде инде. Бу һичшиксез кирәк, ул республика ассоциациясе белән элемтәне дә тәэмин итәчәк, фермерларга үзара киңәшеп аралашып эшләү мөмкинлеге тудырачак. Юкса, мөстәкыйль хуҗалык итү күп сораулар тудыра бит әле. Ә болай фермерлар үз алларына яшиләр. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе дә аларны аерым игътибар белән сөендерми, фермерлар үзләре дә ЦСУга отчет кына бирергә дә авырсыналар. Ә бит продукция җитештерелә икән—димәк, нәтиҗә белән һәркем кызыксынган булырга тиеш.

**—Һәм соңгысы, Рифкать Хатыйпович. Агымдагы елда бер генә яңа фермер хуҗалыгы да оешмаган. Бу нәрсә—фермер хуҗалыклары бетүгә бара дип уйларга каламы?**

—Чыннан да, яңа хуҗалыклар оешмады, гамәлдә булганнарның берсе таркалды да әле. Шуңа карамастан, мин андый нәтиҗә ясарга ашыкмас идем. Безгә калса, бу—вакытлы кыенлыклар, елның тотрыксызлыгыннан туган нәрсә генә. Кыйммәтчелек, бәяләр политикасында пропорциясезлек, билгеле, мөстәкыйль эш башлаучылардан зур тәвәккәллек таләп итә. Икенче яктан, алда әйткәнебезчә, фермерлык хәрәкәтенә җитди, файдалы нәрсә итеп карау да җитенкерәми. Күп колхоз-совхоз җитәкчеләре аларга көндәш, хәтта дошман итеп карый. Ә бит фермерлыкның хуҗалык итүдә яңа, отышлы формасы эзләүдә бер алым икәнен дә онытырга ярамый. Әле декабрьдә колхоз-совхозлар җитәкчеләре белән үткән киңәшмәсендә республика Президенты да шуны ассызыклады.

Һәр колхозда, һәр совхозда запас җир фонды бар, анда мөстәкыйль хуҗалык итәргә теләүче табыла икән, һич тә аяк чалырга түгел, хупларга, булышырга кирәк. Моннан һич кенә дә колхоз-совхозларның дәрәҗәсе төшмәячәк, милек хисе тәрбияләү исә—хәзер бик кирәк нәрсә. Ә фермер булырга теләүчегә киңәшебез шул: теләк кирәк. Теләк, омтылыш булганда бар кыенлыклар да җиңеләер.

**—Рәхмәт, Рифкать Хатыйпович.**

**Әңгәмәне С. ХӘЙРУЛЛИНА алып барды.**

# Кайсыгызның кулы җылы?

Ел ахыры якынлаша. Гадәттә кешеләр бу чор белән үзләренең иң матур хыялларын, иң татлы планнарын бәйлиләр иде. Менә иске ел узар да, өр-яңа елга аяк басарбыз, алда мөнәсәбәтләр дә яңача, уңышлар да зуррак, яшәвебез дә ямьлерәк булыр дигән өметкә күпләр күңелен җылыта иде. Аның әле Яңа ел бәйрәме үзе ни тора? Бәйрәмгә байтак алдан бу ямьле чорга әзерлек мәшәкате һәр нәрсәдә үзен сиздерә: кибет заллары, урамнар купшы итеп бизәлә; бала-чагалар алар өчен әзерләнгән махсус шәһәрчек—олы чыршы янында мәйханә киләләр; әле анда, әле монда чыршы күтәргән өлкәннәр күренә, ә «Балалар дөньясы»нда күз явыңны алырлык купшы, ялтыравыклы уенчыклар, флагчыклар, маскалар, уенчык Кыш бабай, Кар кызы һәм тагы әллә нинди хикмәтләр сатыла.

Әллә нәрсә булды дөньяга. Елдан-ел бәйрәмнәр уңа, йөзләр кырыслана, кесәләр саега бара. Элеккечә эчкерсез самими аралашу, ашкынып хыяллану, ниндидер яктылык, яхшылык көтү югала бара. Һәр нәрсәгә исәп-хисап, көндәлек сорылык иңә. Быел ул аеруча үзен сиздерә. Теләсә-теләмәсә дә күпләр кесәсеннән чыгып бәйрәмнең күпмегә төшәсен санап аһ итә: итенә фәлән сум, шампан шәрабына тагы... Әле балаларга Кыш бабай бүләгенә генә дә ярты хезмәт хакың китәрлек (Гаепләмибез, саранлыктан түгел, нужадан санарга мәҗбүр кешеләр).

Инде 26 декабрь җитеп килсә дә урамнарда, мәйданнарда, сәүдә залларында бәйрәм бизәлеше дә сизелми. Уенчыклар кибетендә ниндидер маскага охшаш кәгазьләр саталар.

—Юк, уенчыклар кайтмады әле,—диделәр сатучылар безнең сорауга. Үзәк мәйданда Чыршы да 26 декабрьдә генә куеласы икән. Теге сорылык үз тамгасын кабатламас. Яңа ел бәйрәменә дә салыр ахрысы. Аның каравы шәһәр базары гөрли.

—Алып калыгыз, Яңа елдан бәяләр тагын ике тапкырга артачак,—диләр сәүдәгәрләр ниндидер эчке тантана белән. И, агай-эне, рәхмәт инде кайгыртуыгызга, дип 25 тәңкәгә чәер, 400 тәңкәгә колготкины егыла-егыла, шатлана-куана алырга тиеш була инде гади халык. Тик шатланырлыклары калды микән күпләрнең? Хәләл акчаларына тормышның очын-очка көчкә ялгап баручыларны хәзер берни белән дә гаҗәпләндереп булмыйдыр инде. Базар икътисады зур нәрсә эшләде: моңарчы сатып алуда әлифне таяк дип белмәгән дистәләгән, йөзләгән, меңләгән намуслы эшче коммерция белән шөгыльләнә башлады. Икенче берәүләр, киләчәк ачлык, кыйммәтчелектән куркып, әйбер җыюга кереште: вермишель, макарон, чәй, юу средстволары, тоз, киемсалым, тагы әллә ниләр белән киштәләр тулды, алай да очраган бер нәрсәне җыюны дәвам иттеләр.

Хәзерге чордан да билгесез, ышанычсыз, таянычсыз елларны өлкәннәр дә хәтерләмиләр. Ә яшәргә кирәк! Ничек? Ничек?

Каян килде соң әле бәйрәм алдыннан гына бу караңгы уйлар башка? Бик тә куасы килә аны күңелдән, кешеләр йөрәгенә сары май булып ятарлык, кечкенә генә булса да өмет уятырлык яхшы хәбәр җиткерәсе килә. Яңа елга шул өметле рухта аяк басасы иде.

Без яшәүдән шуны көтәбез. Гел болай булмаска тиештер, нинди дә булса яңарыш, үзгәрешкә өметләнәседер безгә?!

Күңелнең ерак бер почмагында сизелер-сизелмәс кенә җемелдәп торган ул өметне сүндермисе, тергезәсе иде. Парламентарийлар, эшмәкәрләр, аксакаллар, кайсыгыз ил күңелендәге өметсезлек дигән чуанны бәйләргә әзер? Кайсыгызның кулы җылы?

**С. НУРУЛЛИНА.**



Владимир Викторович «Заря» колхозы товарлыклы-сөтчелек фермасында эшли. Владимир тырыш, эшчән, җитез, үзенә бирелгән эшне үтәмичә, калганы һич кенә дә юк. Ул фермада терлекче булып 15 елдан артык эшли. Владимирның бәхетенә тормыш иптәше дә шундый иде, тырыш кеше туры килде. Ул колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасында уңган сыер савучылардан санала. Ермошкиннар 5 бала тәрбиялиләр. Җитеш, таза, тормышта намуслы хезмәттә үтә аларның гомерләре.

Н. Азизов фотосы.

## 01 хәбәр итә

11 НОЯБРЬДӘ СМУ-53 төзүчеләренең көнкүреш вагоны янды. Кайчандыр төзүчеләр ташлаган вагон балалар өчен табылдык булган. Һәм менә нәтиҗәсе. Ярый әле ут янәшәдә генә урнашкан икмәк заводына күчмәде.

21 НОЯБРЬДӘ Чулпан авылында билгесез берәү мәчет янында салам яндырган. Күрәсең, кешеләр хәзер ходайдан да курыкмый башлаганнар.

29 НОЯБРЬДӘ «40 лет Победы» колхозында гараж түбәсенә ут капты.

30 НОЯБРЬДӘ Егоркино авылында О. П. Наумованың өе янды. Ә бу янгын вакытында Самара өлкәсеннән кунакка кайткан 16 яшьлек Марина һәлак булды. Әлеге фаҗигането сәбәбе—эчкечелек. Бу факт буенча тикшерү бара.

Күргәнегезчә, янгыннарның сәбәпләре төрле, әмма аларның уртак ягы да бар. Һәр очракта да соңгы гаепле булып кеше, аның нәрсәнедер эшләп җиткермәве, игътибарсызлыгы тора. Моның берәр чиге булырмы? Һәм безнең җавапсызлык тагын күпмегә төшәр?

**Н. СӨЛӘЙМАНОВ,**
эчке служба капитаны,
ПСО начальнигы.

